**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 39 03 октябрь 2016 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Әлкәй авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге башлыгының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 26 сентябрендәге 14 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл Советының «референдум үткәрү инициативасы турында»2016 елның 26 сентябрендәге 38 номерлы карарын карап,

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Әлкәй авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 20 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Әлкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2017 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы Сез?:

1) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияләрне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыруны һәм карап тотуны кертеп) - Әлкәй авыл җирлеге торак пунктларының юлларын кардан чистарту, гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме ,

2) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру- гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме күләмендә су белән тәэмин итү буенча проект-смета документациясен эшләү

3) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмасы хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру - гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме күләмендә бәйрәм чаралары оештыру,

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис С.З. Зиннурова